МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ
БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** 20.08.15

г. Казань

**БОЕРЫК** № 663-п

# Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 5 сентябрендәге 505-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитар сак зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 5 сентябрендәге 505-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитар сак зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) кертелә торган, кушымта булып килүче үзгәрешләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның җир асты байлыкларыннан файдалану буенча урынбасары Т.М. Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г.Сидоров

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 5 сентябрендәге 505-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитар сак зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 20 августындагы 663-п номерлы боерыгы белән расланды)**

Административ регламентның 1.3.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Мәгълүмати элмә такталарда урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.”;

Административ регламентның 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Су кодексы, 03.06.2006 № 74-ФЗ (алга таба – РФ СУ) (“РФ законнары җыентыгы”, 05.06.2006, № 23, ст. 2381, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 30.03.1999 №52-ФЗ Федераль закон (алга таба – №52-ФЗ Федераль закон) “РФ законнары җыентыгы”, 05.04.1999, № 14, ст. 1650, “Российская газета”, № 64-65, 06.04.1999, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында” 27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – №210-ФЗ Федераль закон) (“Российская газета”, № 168, 30.07.2010, “РФ законнары җыентыгы”, 02.08.2010, № 31, ст. 417, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Су белән тәэмин итү һәм эчә торган суүткәргеч чыганакларын саклауның санитар зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02” санитар кагыйдәләре һәм нормалары (алга таба – СанПиН 2.1.4.1110-02) (“Российская газета”, №81, 08.05.2002, “Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене”, №19, 13.05.2002, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01” санитар кагыйдәләре (алга таба – СП 2.1.5.1059-01) (“Российская газета”, №172, 05.09.2001, “Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене”, №38, 17.09.2001);

“Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 20.06.2006 №42-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – №42-ТРЗ ТР Законы) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 12.11.2006, №43, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитар сак зоналары проектларын раслау тәртибе хакында” 29.02.2012 №177 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №177 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 24.04.2012, №31, ст. 0963, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 №325 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №325 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 27.07.2005, №28, ст. 0654, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 02.11.2010 №880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №880 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 08.12.2010, №46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

Административ регламентның 1.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“**Техник хата** – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең, алар нигезендә белешмәләр кертелүче документтагы (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) белешмәләрнең төгәлсезлегенә китергән хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

**Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза** (алга таба – гариза) – мөрәҗәгать итүченең №210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 1 п. каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсе.

**Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны** – документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләрне муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә консультацияләү тәрәзәсе.”;

Административ регламентның 2 бүлегендә:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасының аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы”;

“Стандарт таләпләренең эчтәлеге” графасының аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге”;

2.1 пунктында “Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын “№42-ТРЗ ТР Законының 3 ст. 1ө.” сүзләре белән тулыландырырга;

2.3 пунктында “Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан” сүзләрен “Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан” сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктын:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта – дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы”;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “биш көн” сүзләрен “биш эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

2.5 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында “мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшыру” сүзләреннән соң “, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе” сүзләре белән тулыландырырга”;

4 пунктчаның “Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “җир кишәрлеген файдалануга тапшыру турындагы документның” сүзләрен “җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның” сүзләре белән алмаштырырга;

5 пунктчаның “Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “оешманың мөһере белән (юридик затлар өчен)” сүзләреннән алда “Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу бурычы билгеләнгән очракларда” сүзләре белән тулыландырырга;

2.6 пунктында:

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “(Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтендә)” сүзләрен “(Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә)” сүзләре белән алмаштырырга;

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында “мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы” сүзләреннән соң “, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе, әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма” сүзләре белән тулыландырырга;

2.13 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында “дәүләт хезмәтенең” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон рәвештә” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

2.14 пунктында “Стандарт таләбенең аталышы” графасында “дәүләт хезмәте” сүзләреннән соң “, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текст һәм мультимедия мәгълүматларын рәсмиләштерүгә карата” сүзләре белән тулыландырырга;

2.15 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче белән вазифаи затларның хезмәттәшлек итү ешлыгы һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, мәгълүматны дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрдән файдаланып алу мөмкинлеге”;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

Министрлык бинасының җәмәгатьчелек транспортына якын зонада урнашуы;

тиешле күләмдә белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итә торган биналар булу;

мәгълүмати элмә такталарда, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинеты аша алу мөмкинлеге (Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә тапшыру мөмкинлеге гамәлгә ашырылганнан соң).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

документларны кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

белгечләр тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентлар (дәлилле шикаятьләр) булу;

мөрәҗәгать итүченең белгечләр белән хезмәттәшлек итү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда, турыдан туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләүләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны җибәргәндә, почта аша – юк (консультацияләүләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны җибәргәндә, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша:

1. әгәр дә гариза һәм документларның күчермәләре №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – турыдан туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;

2. әгәр дә гариза һәм документларның күчермәләре №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бер мәртәбәдән артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүенең озынлыгы 15 минуттан артып китми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүне исәпкә алып, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www. eco.tatarstan.ru сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында алынырга мөмкин;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.4 №880 ТР МК карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе пунктының “п” пунктчасы”;

2.16 пунктында “Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “электрон имза белән” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән” сүзләренә алмаштырырга;

“*Срок эш көннәрендә исәпләнә” сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентның 3 бүлегендә:

бүлекнең аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны башкаруга карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне)

күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре”;

3.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә”;

3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен, Министрлыкның гидрогеология һәм судан файдалану бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, почта аша, телефон буенча, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы һәм (яки) электрон почта ярдәмендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яки) хат буенча, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән мөрәҗәгатьнең рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән хезмәт.”;

3.3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.”;

3.3.3 пунктының икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.1.1 пунктының икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.1.4 пунктының икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.1.5 пунктының дүртенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.2 пунктында:

“Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә” сүзләрен “Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә” сүзләре белән алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән гарызнамәләр нигезендә мәгълүматлар бирүче белгечләр сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән тәртиптә бирә.”;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар белән тулыландырырга:

“Әлеге пунктта билгеләнүче процедуралар ведомствоара гарызнамә документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага килгән көннән алып биш көн дәвамында башкарыла, әгәр дә федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм алар нигезендә кабул ителгән федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында ведомствоара гарызнамәгә җавап әзерләү һәм җибәрү буенча башка сроклар билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүматлар) яисә Министрлыкка җибәрелгән баш тарту турында белдерүнамә.”;

3.4.4.4 пунктының икенче абзацында “өч көн” сүзләрен “өч эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.4.5 пунктның дүртенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләренә алмаштырырга;

3.4.5.1 пунктының өченче абзацында “өч көн” сүзләрен “өч эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.5.4 пунктның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләренә алмаштырырга;

3.4.5.5 пунктның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләренә алмаштырырга;

3.4.5.6 пунктның дүртенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләренә алмаштырырга;

3.4.5.8 пунктының икенче абзацында “өч көн” сүзләрен “өч эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.5 пункты белән тулыландырырга:

“3.5. Техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.5.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (2 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) җибәрелгән документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) барлыгын таныклый торган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле заты) тарафыннан  шәхсән тапшырыла, яисә почта аша (шул исәптән

электрон почта ярдәмендә), яисә бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

3.5.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы булган белгеч техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кабул итеп ала, гаризаны теркәлгән документлары белән терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнүче процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карау өчен җибәрелгән гариза.

3.5.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.4.5 пунктында каралган процедураларны башкара һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле затына) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле затыннан) техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) булган документның төп нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресы буенча почта аша (электрон почта ярдәмендә), Бүлеккә техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнүче процедура техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) җибәрелгәнлеге турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.”;

Административ регламентны түбәндәге эчтәлекле кушымта белән тулыландырырга:

“

**Татарстан Республикасы территориясендә**
**эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүреш**
**суы белән тәэмин итү өчен файдаланылучы**
**су объектларының санитар сак зоналары**
**проектларын раслау буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтүнең**
**административ регламентына**
**2 кушымта**

Татарстан Республикасының
экология һәм табигый ресурслар министрына

______________________________________

Кемнән:
___________________________________

**Техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

_______________________________________________ дәүләт хезмәтен
(хезмәтнең исеме)

күрсәтекәндә җибәрелгән техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) турында хәбәр итәм.

Болай дип язылган:_______________________________________________
_________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________________
_________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул иткәндә бу карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны түбәндәге E-mail адресына җибәреп:____________;

кәгазьдә, таныкланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча җибәреп: _____________________________________________________.

Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул ителүне исәпкә алып, шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системага салу, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхессезләндерү, ябу, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка гамәлләр) үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан вәкаләт бирелгән затның ризалыгын бирәм.

Әлегесе белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкаләт бирелгән затка кагылышлы, шулай ук түбәндәрәк минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында

билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны бирү вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларга ия.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча түбәндәге телефон аша катнашуга үз ризалыгымны бирәм: ________________________.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | _____________ | (______________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.).». |